**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в статью 15 Закона Республики Татарстан «О регулировании отдельных вопросов в сфере охраны здоровья граждан в Республике Татарстан»

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
21 апреля 2022 года

## Статья 1

Внести в статью 15 Закона Республики Татарстан от 22 декабря 2012 года № 87-ЗРТ «О регулировании отдельных вопросов в сфере охраны здоровья граждан в Республике Татарстан» (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2012, № 12 (I часть); 2013, № 12 (I часть); 2014, № 6 (II часть), № 7; 2015, № 3, № 10 (I часть); 2016, № 3, № 7 – 8; Собрание законодательства Республики Татарстан, 2016, № 25 (часть I); 2017, № 52 (часть I); 2018, № 1 (часть I), № 29 (часть I), № 54 (часть I), № 83 (часть I); 2019, № 28 (часть I); 2020, № 26 (часть I), № 87 (часть I); 2021, № 29 (часть I), № 93 (часть I) изменения, дополнив ее частями 4 и 5 следующего содержания:

«4. Несовершеннолетним при оказании им медицинской помощи могут быть назначены лекарственные препараты, включенные в стандарты медицинской помощи детям и клинические рекомендации и применяемые в соответствии с показателями (характеристиками) лекарственного препарата, не указанными в инструкции по его применению, в соответствии с частью $14^1$ статьи 37 Федерального закона.

5. Лица, страдающие заболеваниями или состояниями (группами заболеваний или состояний), включенными в перечень заболеваний или состояний (групп заболеваний или состояний), установленный уполномоченным федеральным органом исполнительной власти, при достижении ими совершеннолетия вправе до достижения ими возраста двадцати одного года наблюдаться и продолжать лечение в медицинской организации, оказывавшей им до достижения

совершеннолетия медицинскую помощь при таких заболеваниях или состояниях (группах заболеваний или состояний).».

**Статья 2**

Настоящий Закон вступает в силу с 29 июня 2022 года.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ БҮЛЕК
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ

Казань, Кремль
29 апреля 2022 года
№ 28-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2022 елның 21 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» 2012 елның 22 декабрендәге 87-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2012, № 12 (I өлеш); 2013, № 12 (I өлеш); 2014, № 6 (II өлеш), № 7; 2015, № 3, № 10 (I өлеш); 2016, № 3, № 7 – 8; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2016, № 25 (I өлеш); 2017, № 52 (I өлеш); 2018, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 54 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 28 (I өлеш); 2020, № 26 (I өлеш), № 87 (I өлеш); 2021, № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш), аңа түбәндәге эчтәлекле 4 һәм 5 өлешләр өстәп, үзгәрешләр кертергә:

«4. Балигъ булмаганнарга, аларга медицина ярдәме күрсәтелгәндә, Федераль законның 37 статьясындагы $14^1$ өлеше нигезендә балаларга медицина ярдәме күрсәтү стандартларына, клиник рекомендацияләргә кертелгән һәм дару препаратының аны куллану инструкциясендә бәян ителмәгән күрсәтмәләре (характеристикалары) нигезендә кулланыла торган дару препаратлары билгеләнергә мөмкин.

5. Вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы билгеләгән авырулар яисә халәтләр (авырулар яисә халәтләр төркемнәре) исемлегенә кертелгән авырулардан яисә халәтләрдән (авырулар яисә халәтләр төркемнәреннән) интегүче затлар, балигъ булу яшенә җиткәннән соң, егерме бер яшь тулганчы, аларга мондый авырулардан яисә халәтләрдән (авырулар яисә халәтләр төркемнәреннән) балигъ булу яшенә

җиткәнче медицина ярдәме күрсәткән медицина оешмасында күренергә һәм дәвалануны дәвам итәргә хокуклы.».

**2 статья**

Әлеге Закон 2022 елның 29 июненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2022 ел, 29 апрель
№ 28-ТРЗ